РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28. 07. 2020г. с. Сарманово № 229

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ситуацион үзәген төзү турында

Россия Федерациясе Президентының «Үзара хезмәттәшлекнең бердәм регламенты буенча эшләүче бүленгән ситуацион үзәкләр системасын формалаштыру турында» 2013 елның 25 июлендәге 648 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Бүленгән ситуацион үзәген булдыру чаралары турында» 2016 елның 3 ноябрендәге ПУ-982 номерлы Указын үтәү йөзеннән Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ситуацион үзәген булдырырга.
2. 1 нче кушымта нигезендә Сарман муниципаль районының Ситуацион үзәге турындагы нигезләмәне расларга.
3. 2 нче кушымта нигезендә Сарман муниципаль районының Ситуацион үзәге эшчәнлеге турында хисап формасын расларга.
4. Сарман муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарын Сарман муниципаль районының Ситуацион үзәген булдыру һәм аның эшчәнлеге өчен җаваплылык үзәге итеп билгеләргә (Стратегияне гамәлгә ашыру).
5. Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигына Сарман муниципаль районының Ситуацион үзәге администраторы вәкаләтләре бирергә.
6. Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигына ике атна эчендә Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге турындагы нигезләмәгә Сарман муниципаль районы ситуацион үзәге администраторының өстәмә функцияләрен исәпкә алып, үзгәрешләр кертергә кирәк.

7.Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә ситуацион үзәктә эшләгәндә әлеге карарга таянып эш итәргә кирәк.

8. Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә мәгълүмати-аналитик модельләрне таблица нигезендә беркетергә:

| Мәгълүмати-аналитик модель исеме | Бүлекчәнең исеме (җаваплылык үзәге) |
|---|---|
| Кече эшмәкәрлек субъектларының тулай территориаль продуктка йогынтысын бәяләү | Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге |
| Хезмәт хакын минималь хезмәт хакы күләменә җиткерү йогынтысын бәяләү | Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге |
| Муниципаль район бюджетына НДФЛ күчерү нормативын фаразлау | Сарман муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы |
| Муниципаль берәмлекнең хуҗалык итүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына чагыштырма анализ | Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге |

9. Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары җаваплы структур бүлекчәләр җитәкчеләре белән берлектә айлык срокта:

мәгълүмат ресурслары паспортларын һәм мәгълүмати-аналитик модельләрне эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә аларны мәгълүмат ресурслары реестрына һәм Татарстан Республикасы Бүленгән ситуацион үзәгенең мәгълүмати-аналитик модельләренә кертергә;

Сарман муниципаль районының Ситуацион үзәгендә мәгълүмат ресурсларын һәм мәгълүмати-аналитик модельләрне формалаштыру һәм актуальләштерү регламентын эшләү һәм раслауга кертү;

Сарман муниципаль районының ситуацион үзәгенең мәгълүматлар базасына эштә кулланыла торган мәгълүмат ресурсларын кертергә һәм аларны актуальләштерүне тәэмин итәргә, шулай ук алга таба мәгълүмат-аналитик модельләр эшләү өчен кирәкле беренчел мәгълүматларны актуальләштерүне тәэмин итәргә;

мәгълүматлар базасын һәм модельләрне администрацияләү өчен җаваплы хезмәткәрләрне беркетергә.

10. Җаваплы структур бүлекчәләргә паспортларында күрсәтелгән модельләрне актуальләштерү чоры нигезендә актуаль торышта мәгълүмати-аналитик модельләрне саклауны тәэмин итәргә.

11. Сарман муниципаль районының Ситуацион үзәк администраторына кварталга бер тапкыр отчет тапшырырга.

12. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сарман муниципаль районы мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

13. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкче вазыйфаларын башкаручы Г.А.Галимова